**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә**
**муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**“08” ноябрь 2018 нче ел** **№ 42-240**

**“2018 нче елда “2016-2021 нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен” гамәлгә ашыру барышы турында һәм 2019 нчы елга бурычлар”**

Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Исхакова Л. К.ның “2018 нче елда “2016-2021нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен” гамәлгә ашыру барышы турында һәм 2019 нчы елга бурычлар” турында докладын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары Исхакова Л. К.ның “2018 нче елда “2016-2021нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы социаль-икътисадый үсеше стратегиясен” гамәлгә ашыру барышы турында һәм 2019 нчы елга бурычлар” турында докладын игътибарга алырга.

2. Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына, Яңа Чишмә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына, районның предприятие һәм оешмаларына тәкъдим итәргә:

- эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен уңай шартлар тудыруга, инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен дәүләт һәм шәхси инвестицияләрне җәлеп итүгә, төп капиталга инвестицияләр кертүгә ярдәм итәргә;
- авыл җирлекләренең тотрыклы үсешенә, Яңа Чишмә муниципаль районы халкының мәшгульлеген һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрүгә ярдәм итәргә;
-беренчел медик-санитар ярдәм күрсәтүче медицина оешмаларының халык өчен уңайлы булуын тәэмин итәргә, күрсәтелгән медицина оешмаларына гражданнар мөрәҗәгать иткәндә чират көтү вакытын кыскартырга, табибка кабул итүгә язылу процедурасын гадиләштерергә;
- халыкның барлык категорияләре һәм төркемнәре өчен физик культура һәм спорт, массакүләм спорт белән шөгыльләнү өчен шартлар тудырырга;
- төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү дәрәҗәләрендә уку-укыту һәм тәрбия бирүнең яңа ысулларын, белем бирү процессына җәлеп ителүне һәм өйрәтүне тәэмин

итә торган белем бирү технологияләрен кертергә, шулай ук “Технология” фәне өлкәсендә укытуның эчтәлеген һәм методларын камилләштерергә;
- хезмәткәрләрнең хезмәт хакын арттыруга һәм аны легальләштерүгә ярдәм итәргә;
- район халкына мәдәният өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген һәм сыйфатын арттырырга;
- “2016-2021 нче елларга һәм 2030 нчы елга кадәрге план чорына Яңа Чишмә муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше стратегиясе” н уңышлы гамәлгә ашыруга ярдәм итүче төп күрсәткечләрнең 2018 нче һәм алдагы елларда үтәлүенә ирешергә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә http://novosheshminsk.tatarstan.ru/.бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы** **Козлов В.М.**